КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 17 май г.Казань № 398

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасында санитар-эпидемиологик хәлне һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу үзенчәлекләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 10 май, 374 нче карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Әлеге чикләү түбәндәгеләргә кагылмый:

музейлар, китапханәләр эшенә, шулай ук индивидуаль яки иң күбе 5 кешедән, ә экскурсия эшен алып бару өчен махсуслаштырылган радиоҗиһаз булганда иң күбе 10 кешедән торган төркемнәргә экскурсия хезмәтләре күрсәтүгә;

профессиональ спортчыларга һәм Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең спорт төрләре буенча җыелма командалары әгъзалары – спортчыларына ачык һавада күнекмәләр ясауга;

бер үк вакытта иң күбе 2 кеше катнашу һәм күнекмәләр ясаучылар арасында кимендә 5 метр ераклык булу шарты белән гражданнарның ачык һавада физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүләренә (әлеге шөгыльләнүләрне паркларда, урман паркларында, скверларда, күпфатирлы йортлар ишегалларында урнашкан балалар уен мәйданчыкларында, балалар мәйданчыкларында, спорт мәйданчыкларында үткәрүдән тыш).»;

4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. 2020 елның 26 мартыннан санитар-эпидемиологик хәл яхшырганга кадәр түбәндәгеләр эшчәнлеген туктатырга:

а) спорт үзәкләре, йөзү бассейннары, фитнес-үзәкләр (бер тренер бер үк вакытта иң күбе бер кеше белән күнекмәләр ясау шартын үтәп, шәхси тренер белән индивидуаль күнекмәләр ясаудан тыш);

б) кинотеатрлар (кинозаллар), төнге клублар (дискотекалар), балалар уен бүлмәләре, балалар күңел ачу үзәкләре һәм башка күңел ачу оешмалары.»;

5 нче пунктның «а» пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«тыштан (урамнан) аерым керү юлы булганда, килүчеләр өчен сәүдә залының файдалану мәйданы 400 кв.метрга кадәр булган азык-төлек булмаган товарлар белән ваклап сәүдә итү объектларыннан тыш).».

2. Бу карар 2020 елның 18 маеннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин